# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LXIII УТЫРЫШЫ

**К А Р А Р № 108**

Мөслим авылы « 17 » апрель 2024 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Мөслим авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне каларга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Мөслим авыл җирлеге Башлыгы** **А.Р.Хуҗин**